Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXXVI-6**

Балык Бистәсе штп.

2023 елның 13 апреле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 23 апрелендәге «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү хакында, шулай ук «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү хакында» X-4 карарының үз көчен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 23 апрелендәге «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү хакында, шулай ук «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү хакында» X-4 карарын;

«Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 16 ноябрендәге XIII-6 карарының 2 пунктын;

«Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре аларны белгәндә керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшырырга, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре хакында мәгълүматлар тапшырырга тиешле муниципаль хезмәт вазыйфаларының Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 23 апрелендәге X-4 номерлы карары белән расланган исемлегенә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017 елның 24 июлендәге XX-6 номерлы карарын;

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 23 апрелендәге «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү хакында, шулай ук «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү хакында» X-4 карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017 елның 22 августындагы XXI-1 номерлы карарын;

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 23 апрелендәге «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү хакында, шулай ук «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү хакында» X-4 карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2021 елның 28 июнендәге X-5 номерлы карарын;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

Р.Р. Ислямов